Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

17 апрель 2023 ел № 2

Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кама-Исмәгыйль авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 31нче августындагы 13 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турында» 2021 елның 12 маендагы 55нче номерлы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы карары, 2022 елның 1 мартыннан кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турындагы килешү нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2023 елның 10нчы апрелендәге 02-08-01/161 номерлы протестын карап

Кама-Исмәгыйль авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Кама-Исмәгыйль авыл башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Кама-Исмәгыйль авыл башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында» 2011 елның 31нче августындагы 13 номерлы карарының үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Кама-Исмәгыйль авылы, Ленин урамы, 92а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Кама-Исмәгыйль авыл
башкарма комитеты җитәкчесе А.З.Шайдуллина